СОВЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Карар — Решение

“20” ноябрь, 2018ел. — №4-39

2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән
җирле референдумда кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә үткәрелгән җирле референдум нәтиҗәләре нигезендә бирелгән сорауга:

«2019 елда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 400 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?:

1. Җирлек чикләрендә су белән тәэмин итү,

- Түбән Сон т. п. да су белән тәэмин итү челтәрен реконструкцияләү ;
- су алу скважинасына тирән насос сатып алу һәм урнаштыру.

.2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге::

- Түбән Сон авылы торак пунктында К.Маркс, Голубое Озеро урамына вак таш җәеп ремонтлау;

. җирлек торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

3. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Колышчы авылында ял паркын корылма белән әйләндереп алу;

«ӘЙЕ» — «ЮК»

Татарстан Республикасы Мамадыш муницпаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге 903 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында»карарын теркәргә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе .Ш.Гафиятуллин